وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللّٰهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№11 (154). 14 сентябрь 2012 / 27-шәүвәл-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Мәдрәсәләрнең татар мәгърифәтенә керткән өлеше

▷3◁



Күңел җылылары суынмасын

▷3◁



"Фәнис" мәдрәсәсе шәкертләр кабул итүен дәвам иттерә

▷4◁

## БИСМИЛЛӘҺИР-РАХМӘНИР-РАХИМ!

**Хөрмәтле дин кардәшләрем, Аллаһы Тәгалә сугышларны тыйган дүрт айның өченчесе - Зөлкагдә ае башлана. Хәзерге каршылыклар туып торган заманда ислам дине кушкан гади генә таләпләрне үтәү дә күп кенә кешеләр өчен кыенлаша бара. Йөрәкләребез белән омтылырга тиешле тынычлык, шайтан котыртуы аркасында бөтенләй бозылып куя язды: Россиягә яраклаштырылган Көнбатыш демократиясе, изге нәрсәләрне мәсхәрәләү, дин әһелләрен үтерү, кануннарга буйсынырга теләмәү, "чиста ислам" өчен көрәш дип дин кардәшләребезне юк итүче мөселманнарның масаюы һәм башкалар күзәтелә башлады.**

**Югыйсә бу изге ай безгә бик үк ошап бетмәгән, ләкин Аллаһы Тәгалә яраткан хәлләрне тыйнаклык белән кабул итәргә кирәклеген искә төшерә: "Шулай да була: кайбер нәрсәләрне сез сөймисез, ә ул сезнең өчен файдалы; кайчак сез үзегезгә зарарлы булганнарны да сөясез. Боларның барысын да Аллаһ белә, сез белмисез". ("Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 216 нчы аяте).**

**Аллаһы Тәгалә алдында барыбыз да тигез. Кемнең җәннәткә, кемнең җәһәннәмгә эләгүе безгә билгеле түгел. Шуңа күрә кешеләрнең шәхси йөзләрен мыскыл итеп, сүзләрендә хаталар эзләп, уй-фикерләре өчен гаепләргә тырышмыйк. Гамәлләр, бары тик кылган гамәлләр генә кемнең кем икәнен аңларга ярдәм итә. Кеше үтерүче нәрсә генә сөйләмәсен, күпме генә намаз укымасын, аның гамәле - кеше үтерү - бик зур аяныч хәл. Аллаһы Тәгалә үзе ярлыкасын һәм гөнаһлар кылудан сакласын.**

**Мөселманнарны артык агрессиядә гаеплиләр, ә без һәрвакыт ислам диненең тынычлык дине булуын аңлатып торабыз. Аллаһы Тәгалә юкка гына сугыш һәм бәрелешләр тыелган айларны билгеләмәгән. Шулай итеп, Ул гел сугышып торучы халыкларда тыныч тормышка мәхәббәт уяткан. Бүген бу бигрәк тә әһәмиятле, чөнки сугышлар урынына террорлык башланды. Террорчыларның дине юк, ләкин, кызганыч, вәхшилекләр ислам дине байрагы астында кылына икән, кешеләр мөселманнар турында начар уйлыйлар. Моннан чыгып, алар мөселманнардан һәрвакыт шикләнә, хәтта аларны күрә алмый башлыйлар. Без нәрсә эшләргә тиеш соң?! Митингларга чыгып, безне яратуларын таләп итәргәме?! Әллә үз мисалыбызда мөселман кешесенең сүзләре белән гамәлләре туры килүне, рәсүлебез Мөхәммәт (сгв) кебек тыйнак, игелекле, ярдәмчел, тынычлыкка омтылучан булуны үрнәк итеп күрсәтергә тырышыргамы?! Әлбәттә, нәкъ шулай, барчабыз да уңай, изге, бары тик тыныч тормышка өнди торган гамәлләр кылып, шул гамәлләребез аша исламга чакырып, рухи кыйммәтләрне дәгъватлап яшәргә тиешбез. "Сез шундый фетнәләрдән куркыгыз, ул фетнәләр бары тик залимнәргә генә кагылмас (барыгызны да тар-мар итәр), белегез ки, Аллаһның газабы дәһшәтледер" ("Әнфал (Табыш малы)" сүрәсенең 25 нче аяте).**

*Үзәкләшкән дини оешма -*
*ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,*
*мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

## "Алтын урта" яңа сезонын ачты

**6 сентябрь көнне Казан шәһәренең Мәрҗани мәчетендә "Алтын урта" татар мөселман яшьләре җәмгыятенең чираттагы сезонын ачу тантанасы булды.**

Чара мәчетнең конференц-залында үтте. Башта РИУ шәкерте Илнур Нуриев Коръәннән аятьләр укыды, соңыннан "Сорнай" төркеме һәм Рәдиф Әхмәдиев башкаруында мөнәҗәт тыңладылар. "Libertas" төркеме рэп укыды. Шулай ук Рафис Сәйфуллин Бөгелмә шәһәрендәге "Алтын урта" җәмгыятенең филиалы һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге эшчәнлекләренә багышланган презентация күрсәтте. Чараны мөфтиятнең яшьләр белән эшләү бүлеге белгече Акйолдыз алып барды.

Сезон ачылышында ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Аппарат җитәкчесе Ришат Хәмидуллин, Мәдинә мәчетенең имам-хатыйбы ярдәмчесе Сиражетдин Нәбиев чыгыш ясады. Кунаклар арасында Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе Тәбриз Яруллин, Россия стратегик тикшеренүләр институтының Идел буе дини һәм этнодини тикшеренүләр үзәге җитәкчесе Рәис Сөләйманов, яшь шагыйрь Фәнил Гыйләҗев та бар иде.

Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәйз исеменнән республикабызның актив яшьләренә - Айнур Солтановка, Ләйсән Фәтхетдиноавага, Рафис Сәйфуллинга, Фәрхәд Миңнехановка, Илнур Нуриевка, Рафис Гайнетдиновка, Сөембикә Саттаровага, Камил Шәриповка, Рөстәм Смирновка, Хәдичә Хәйдәрәлиевага, Венера Галәветдиновага - күп чараларны башлап йөрүләре өчен, рәхмәт хатлары тапшырылды.

**P.S.:** 22 сентябрьдә "Автомобильләрсез көн" узачак. Бу чарада мөселман яшьләре дә катнашыр, дип тә көтелә. Яшьләрне ТР Диния нәзарәтендә көндезге сәгать икедә (14.00) көтеп калабыз.



## Яңа китап: "XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый"

**Соңгы дистә елларда дөньяда суфичылык, суфи әдәбияты белән кызыксыну шактый артты, һәм бу, иң беренче чиратта, әлеге серле һәм һич аңлатып бетереп булмый торган тәгълиматның мөселман халыкларының рухи тормышында аерым бер роль уйнаганын аңлау белән бәйле. Урал-Идел буе төбәгенең күп кенә суфи шагыйрьләренең иҗаты аз өйрәнелгән булып кала бирә, бу җәһәттән Мәүла Колый шигърияте дә искәрмә түгел. Бу олуг шагыйрьнең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүгә филология фәннәре кандидаты, профессор Камил ага Дәүләтшин зур өлеш кертте.**

Шунда ук билгеләп китик, К.С. Дәүләтшин кебек, кульязмалар белән эшләүче һәм югары профессиональ дәрәҗәдә эшли белүче текстолог галимнәр бик сирәк. Галим шагыйрьнең шигъри текстларын өйрәнү буенча җитди һәм бик җентекле текстологик эш башкарган (Дәүләтшин К.С. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый: Уку кулланмасы / К.С. Дәүләтшин. - Уфа: РИЦ БашГУ, 2010. - 398 б.). Һәр битнең аскы өлешендә барлык гарәп, фарсы, төрки сүзләрнең тәрҗемәсе кителгән. Билгеле булганча, Урал-Идел буе төбәгенең бу чордагы төрки әдәби теле халык массалары өчен аңлаешлы булмаган, бары тик җәмгыятьнең укымышлы өлеше тарафыннан гына файдаланылган.

К.С. Дәүләтшин тикшерүләренең әһәмиятле яклары - анда әдәбияттагы тарихилык принципларына зур урын бирелүе. Бу авторның эрудициясен (киң белемлелеген), югары профессиональлеген күрсәтә. Чынлап та, теге яки бу автор әсәрләрен өйрәнгән вакытта, теге шагыйрь яки бу язучыны, шәхес буларак, үзе яшәгән, үзе иҗат иткән заманнан аерып карау дөрес булмас иде.

XVII гасыр - давыллы халык ихтиляллары (революция) заманы. М.Колый, дипломатларча оста, конфликтларны һәм "үткен почмак"ларны урап үтеп, үз халкы тарыган авыр хәлдән чыгу юлларын эзли. Идел буе халыклары да актив катнашкан Степан Разин (1670-1671) ихтилалын (баш күтәрүен, сугышын) бастырганнан соң татарларда көчәеп киткән өметсезлек, күңел төшенкелеге фонында, М.Колыйның җирдә эшләүчеләрнең хезмәтен олылап, мактап язган әсәрләре актуаль яңгырый. Шагыйрь өметсезлек һәм мохтаҗлык кичерүче гади халыкны нәтиҗәле тормыш алып баруга чакыра. "Әгъзаларның нәфис нигъмәт булуын (юкка гына түгел) аңла! Гамәл кыл!", - дип өнди ул.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

**"АК МӘЧЕТ" МӘДРӘСӘСЕНДӘ АЧЫК ДӘРЕС ҮТКӘРЕЛДЕ**

**11 сентябрь көнне Чаллы шәһәренең "Ак мәчет" мәдрәсәсендә ачык дәрес үткәрелде.**

Дәресне мәдрәсә укытучысы һәм Алабуга шәһәренең Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы Азат хәзрәт Шәрипов алып барды. Ул "Ислам диненең террорчылыкка һәм фанатиклыкка карата мөнәсәбәте" дигән темага вәгазь укыды. Хәзрәт гади мисаллар китереп, тыңлаучыларга ислам диненең шәфкатьлелек, рәхимлелек дине икәнлеген аңлатты. "Динебездә көчләү, фанатиклык, экстремизм, террорчылык, кешеләрне куркыту һәм аларның милкенә кул сузуга урын юк", - диде ул.

Шулай ук хәзрәт дини гыйлем туплауның әһәмияте һәм бары тик махсус дини белемлеләрнең генә башкаларга динне аңлатырга хокуклы икәнен әйтеп үтте: "Ислам динен без кичә генә кабул итмәдек, борынгы бабаларыбыз мең ел элек исламга килгәннәр: биш вакыт намаз укыгыннар, хәмер эчмәгәннәр һәм бүгенге көндә җәмгыятьтә таралган гөнаһларны кылмаганнар. Бу дингә пәйгамбәребез Мөхәммәт (сгв) өндәгән һәм безгә дә шушы традицион ислам диненә тартылырга кирәк".

Азат хәзрәт шәкертләргә мөрәҗәгать итеп, болай диде: "Сезгә зур өметләр баглана, башкаларга дини кыйммәтләрне җиткерерсез. Шуңа да белем алуга һәм холкыгызны тәрбияләргә күп көч куегыз".

**М.ИМАНКОЛЫЙНЫ ИСКӘ АЛДЫЛАР**

**10 сентябрь көнне бөек татар галиме, дин әһеле, Казан шәһәренең имам-мөхтәсибе Мөхәммәдсадыйк Иманколыйның тууына 142 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция узды.** Кичәдә ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм "Алтын урта" татар мөселман яшьләре докладлар белән чыгыш ясады. Галимнең оныгы Гөлчирә Иманкулова да бабасы турында истәлекләре белән уртаклашты, аннан калган мирас белән таныштырды. Чара Карьер бистәсендә урнашкан Коддус мәчетендә узды. Конференцияне оештыручы, мәчетнең имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин да чыгыш ясады, М.Иманколыйның рухына дога кылып, бу чараның киләсе елларда да дәвамлы булуына өмет белдерде.

**ИМАМ-ХАТЫЙБНЫ СОҢГЫ ЮЛГА ОЗАТТЫЛАР**

**7 сентябрьдә 78 яшендә Кайбыч районының Морза Бәрлебашы авылы имам-хатыйбы Зәйнулла Әфләтунов вафат булды.** Ул әлеге мәхәлләне 2006 елдан җитәкли башлаган иде. "Олы яшьтә булуына да карамастан, мөхтәсибәт үткәргән барлык чараларда катнашып, үзенә йөкләнгән вазифаны җиренә җиткереп башкарып килде", - диелә район мөхтәсибәте хәбәрендә.


*Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**1 сентябрьдән 2013 елның I яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу башланды. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

# Яңа китап: "XVII гасыр шагыйре Мәүлә Колый"

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)**




Суфичылык тәгълиматы буенча, рухи камиллеккә ирешү юлы - ул Аллаһның сөюе белән хезмәт, әмма, "Суфичылык әдәбиятын өйрәнүче галимнәр, Аллаһның сөюенә зур урын бирәләр, ләкин, шул ук вакытта, хезмәткә чакыру темасының да мөһим булуын игътибарсыз калдыралар", - дип яза К.С. Дәүләтшин. Тикшерүче бу бушлыкны тутырып куя.

М.Колый иҗатына өстән-өстән, берьяклы гына бәя бирелгән уку дәреслекләрен автор бик нигезле тәнкыйть итә. Ә бу берьяклы бәя бирүләр шагыйрьнең дини-философик карашларын гуманистик идеаллар белән каршы куяю фонында җиткерелгәннәр. Шиксез, Россия галимнәренең суфичылык әдәбиятына андый берьяклы карашы, мистик әсәрләренә бәя биргән вакыттагы методологик төгәлсезлекләр, болар барысы да илебездә суфичылык кебек катлаулы һәм күпкырлы фәлсәфи-дини тәгълиматның җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәвен күрсәтә.

Китап авторы, барысын да тузгыткан крестьяннар ихтилаллары һәм Рәсәй патша хөкүмәтенең татарларны массакүләм кысуга күчкән бу чорда, татар халкы әдәби дөньясында яңадан-яңа күренекле әсәрләр барлыкка килгән, дип бик дөрес билгеләп китә. Шунысын да өстәп әйтик, татарлар тормышының бу авыр дәверендә суфичылык ислам динен, татар халкының милли үзаңын саклап калуда да гаять зур роль уйнаган. Кешеләрчә чын хәят эзләп, татарлар, алар өчен христиан дөньясын гәүдәләндергән рус җәмгыяте кысаларында, рус җәмгыяте белән Идел буе һәм Урал мөселманнары тарихында берничә тапкыр трагик формалар алган мәдәни ассимиляциягә дучар булырга теләмәгәннәр. Шуңа да, безнең ата-бабаларыбыз рус патша хакимлеге тарафыннан милли һәм сәяси золымга дучар булган ул вакытларда, шагыйрьләр, үз сүзләренең чын мәгънәсен яшерү максатыннан, кинаяле, аллегорик мәгънәле гыйбарәләргә мөрәҗәгать итеп, суфичылык юнәлешендәге әсәрләр иҗат итәргә мәҗбүр булганнар.

К.С. Дәүләтшин хезмәтендә, аның башка тикшерүчеләр белән бәхәс кузгатып (шагыйрьнең биографиясе турындагы материалларның бик ярлы булуына да карамастан) һәм дә анык бер логик эзлеклелектә барып, авторның "Меллагол" һәм "Мәүлә Колый" тәхәллүсләре (псевдонимнары) кулланып иҗат итү сәбәпләрен аңлатуы да уңай күренеш булып тора. К.С. Дәүләтшин моны, иң беренче чиратта, шагыйрьнең үз иҗатына карашы үзгәрү һәм илдәге иҗтимагый-сәяси хәл белән бәйли: Степан Разин ихтилалы (крестьяннар сугышы), аның аяусыз бастырылуы, аннан соң башланып киткән массакүләм эзәрлекләүләр, халыкны кысу, золым, һәм дә шуның нәтиҗәсе буларак, халыктагы рухи төшенкелек халәте, өметсезлек. Моның белән килешми дә булмый. Ләкин К.С. Дәүләтшин шунысын күздән ычкындырып җибәрә: Бәйрәмгали Колыев (шагыйрьнең чын исем-фамилиясе, халыкта аны Бимкә суфи дип тә атаганнар), иң беренче чиратта суфи шагыйрь булган, шуңа да, аның бер "Меллагол" тәхәллүсеннән (ул "укымышлы" дигәнне аңлата) икенче "Мәүлә Колый"га ("Алла колы") күчүе, чынлыкта исә, - мөгаен аның, камиллеккә ирешү юлын (суфичылык мәкамнәрен) үтеп чыгуы (үзенә күрә үтеп чыгуы) булгандыр.

Совет хакимияте вакытында Исламга карата мөнәсәбәтләрдә урнашкан методологик стереотиплар, идеологик һәм психологик тискәре фикерләр бүгенге көнгә дә азагына кадәр бетерелмәгән әле. Фәнни-тикшеренү хезмәтләрендә суфичылыкны, "урта гасырларның феодаль җәмгыяте өчен хас булган агым" буларак, алгарыш һәм мәгърифәт тарату идеяләренә каршы куя хәзерге көнгә кадәр дәвам итә. Мәсәлән, суфи шагыйрьләр иҗаты турында сүз алып барганда, кайбер тикшеренүчеләр алар иҗатының суфича юнәлеш алуын шул заманнар тәэсире, шул вакытта урнашкан тарихи вазгыять һ. б. белән аңлаталар һәм шул ук вакытта, акланган кебек, бу әсәрләрнең прогрессив якларын да күрсәтеп китәләр. Кызганыч, К.С. Дәүләтшин китабы да андый мизгелләрдән азат түгел. Мәүлә Колый иҗатында дөньяви мотивлар барлыгын шик астына алган мәктәп уку дәреслекләре авторлары белән сүз көрәштереп, К.С. Дәүләтшин, мәсәлән, болай дип яза: "Монда бер мөһим момент искә алынмый - борынгы әдәби әсәрләрдә прогрессив идеяләр, бер агымга кушылып, авторның мистик һәм утопик карашлары белән бер яссылыкта биреләләр. Бу күренеш Мәүлә Колый иҗаты мисалында да күзәтелә. Аның иҗатында капма-каршы идеяләр һәм капма-каршы карашлар бик күп. Ләкин алар арасында прогрессив идеяләрне алга сөргән, дөньяви мотивлар белән сугарылган шигырьләр дә бар". Мондый караш тамырдан дөрес түгел, чөнки суфичылык, әдәбияттагы дини-философик агым буларак, Идел буе һәм Урал халыкларында фәлсәфи фикер барлыкка килүдә гаять зур роль уйнаган, һәм дә, Мәүлә Колый кебек олуг суфи шагыйрьнең иҗаты турында сүз йөрткәндә аның бу юнәлештәге ролен киметеп күрсәтү, йомшак итеп кенә әйткәндә, гадел булмас иде.

Шулай ук, галим К.С. Дәүләтшинның Мәүлә Колыйның тормышта суфи булу-булмавы турындагы фикерләре белән дә килешеп булмый. Ул "Мәүлә Колый фани дөньядан баш тартып, тарикать юлына баскан дәрвиш суфи булмаган, ә укымышлы суфичылык галиме, үз заманы өчен билгеле фәлсәфәче, эшлекле шәхес, хәтта, бервакыт, Биләр татарларын оештыручы да булып торган. Шуңа да, бернинди шиксез, андый кеше, тормышта суфи була алмаган, ул мөтәсәвүф-философ булган". Беренчедән, галимнең суфичылыкны ике төргә: чынбарлыкта суфи (суфичылык) һәм "тасаувыф" (пантеистик суфи тормышы алып баручы фәлсәфә тарафдары) дигән төшенчәгә бүлүе - үзе үк ялгыш булып тора; суфичылык һәм тасаувыф - чынбарлыкта бер үк философик-дини тәгълимат; бу ике атама арасындагы аерма бары тик шунда: тасаувыф - төгәлрәк вариант. Ләкин суфичылык идеяләре эчтәлеге буенча күптөрле, күпйөзле - ул гомумән башка. Әгәр дә, мәсәлән, Иран суфичылыгы - оппозиция характерында булса, гарәп суфичылыгы - калыплашкан, күбрәк бер динле кануннарга буйсына. Идел буе һәм Урал төбәгендәге мистик тәгълимат исә бу "өчберлектә" "алтын урталыкта" тора. Шулай итеп, хәнәфи мәзһәбенең күренекле галиме Хуҗа Әхрар (Гобәйдулла Хуҗа Әхрар, 1404-1490) нигез итеп алган "игътидалә тарикате" (уртачыл суфизм) Урал-Идел буе төбәгендә киң таралыш алган төп юнәлеш була да инде. Икенчедән, югарыда автордан китерелгән өземтәдә суфичылыкны бары тик аскетик, дөньядан аерылган агым итеп аңлатырга тырышу аермачык сизелеп тора. Шуннан нәтиҗә дә ясыйбыз: "Мәүлә Колый суфиларча көн итүче була алмаган, чөнки ул тормышта пассив түгел, ә иҗтимагый актив яшәеш рәвешен алга сөрә". Кызганыч, илебездәге әдәбият белеме фәнендә андый ялгышу хәзергә кадәр яши әле. Татар суфи шагыйрьләре (Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Мәүлә Колый, Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари, Әбелмәних Каргалый һ. б.) иҗатында очрый торган гадәти суфичылык мотивы тәрк әддүнйа (фани дөньяны санга сукмау, кире кагу) рухи кыйммәтләрне матди кыйммәтләрдән өстен чагылдыралар, һич тә аскетизмга, фани дөньядан баш тартырга чакырмыйлар, гәрчә күпләр шулай күз алдына китерергә тырышса да.

Болардан тыш, дөнья рәхәтеннән ваз кичү, ялгызлыкны ярату белән мавыгулар суфичылыкның бары тик баштагы дәверендә генә (IX-XII гасырларда гына) - Хәсән әл-Басрый, Җүнәйд әл-Багдади, Зөн-Нүн әл-Мисрый, Рабига әл-Гадәвийә кебек гарәп мистик шагыйрьләре иҗатында өстенлек алган. Соңрак дәверләрдә, безнең очракта XVII гасыр турында сүз бара, аскетизм мотивлары акрынлап авторларның актив гражданлык карашлары белән алышына. Үз халкының авыр хәлдә калуына борчылу, килеп туган бу тарихи вазгыятьтән, ярлы икътисади хәлгә бәйле эчке шәхси каршылыктан чыгу юлларын эзләү һ. б. алгы планга чыга. Ә аскетизмда - күпчелек үз-үзенә мөкиббән китү омтылышлары өстенлек ала; кешеләр дөньясыннан аерылган аскетларны үз җаннарының котылып калуы күбрәк борчый. Чынбарлыкта, күп кенә төрки һәм татар суфи шагыйрьләре, гомумкешелекнең бөек максатлары - рухи азатлык, туганлык, гаделлек хакында чыгыш ясап, үз халыклары мәнфәгатьләрен нык яклаучылар булып та чыгыш ясаганнар. Башкача мөмкин дә булмаган, чөнки, катлаулы кискен үзгәреш вакытларында, хакимият белән кискен каршылыкны сайлауга караганда, үзара килешүгә бару кулайрак булган. Соңгы омтылыш суфичылыкның Урал-Идел буе вариантында - бу төбәктә суфичылыкның югары үсештәге чорында - XIX-XX йөз башында вәисчеләр хәрәкәте чорында аеруча ачык чагыла. Кыю фикерләре һәм ирек турындагы идеяләре өчен кайбер татар мистик шагыйрьләренең эзәрлекләнүләре, төрле җәберләүләргә, репрессияләргә дучар ителү очракларын, шулай ук, беркем дә кире какмый.

Бу теманы дәвам итеп, К.С. Дәүләтшинның, мистик агым буларак, суфичылык турында тискәре төсмердә әйтелгән тагын бер фикерен китерергә була: "Әгәр дә башкарылырга тиешле бар дини-мистик кагыйдәләрне дә үтәп бетергән очракта, кешегә калган дөньядан аерым яшәүдән башка чара калмый. Бу - кеше өчен үз мәнфәгатьләрен, кыргыйларча, җәмәгать тәртипләренә каршы куюга әйләнә, һәм соңгы нәтиҗәдә, җәмгыятьнең һәм шәхси тормышның тулысынча җимерелүенә китерә". Чынбарлыкта исә, күп кенә суфи шагыйрьләр дөньяви рухлы кешеләр булганнар, гаиләләр корганнар; суфичылык тарафдарлары булып калуларын дәвам итеп, шул ук вакытта алар зекер кылганнар, үгет-нәсыйхәт белән шөгыльләнгәннәр, рухи үсештә камиллеккә омтылышларын дәвам иткәннәр. Җәмәгать эшләрендә актив катнашып, карап торышка алар гадәти тормыш алып барганнар. Боларның барысына өстәп, Урал-Идел буе төбәге суфиларының үз халыклары азатлыгы һәм хокуклары өчен көрәшүчеләр булуы турында да күп мисаллар китерергә була: Мәүлә Колый (XVII гасыр), Габденнасыйр әл-Курсави (1776-1812), Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари (1754-1834), Габделҗаббар Кандалый (1797-1860), Таҗетдин Ялчыгол (1768-1838), Шәмсетдин Күлтәси (1856-1930), Әхмәтҗан Тубыли (1825-189?), Мифтахетдин Акмулла (1831-1895), Зәйнулла Рәсүлев (Зәйнулла ишан) (1833-1917) һ. б. Аларның күбесе патша режимы тарафыннан эзәрлекләнгән, җәзаланган, төрмә тоткынлыгының авырлыкларын да татыган. Идел буе белән Урал суфиларының шундый нәтиҗәле иҗтимагый эшчәнлек алып баруларының сәбәбе - алар нәкышбәнди тарикатенең унбер нигезенең берсе - "хәлват дәр-әнҗүман" ("кешеләр арасында булсаң да, ялгызлыкта булу") тарафдарлары булганнар. Әлеге канун кешеләр белән аралашуга да карамастан, ялгызлык халәтендә калуны аңлата. Бу канун асылын шулай тасвирларга була: "Куллар табышка юнәлә, җан - Сөеклегә омтыла", ягъни, җан һәм йөрәк Хак Аллаһ турында уй белән уратылган, ә шул ук вакытта, тән һәм тышкы гамәлләр - Аның тарафыннан яратылган шул дөнья эшләрендә. Баһаветдин Нәкышбәндинең карашлары нәкышбәндиянең бар тармаклары өчен дә бердәм булып кала. Хакимияткә карашны билгеләгән канун гына искәрмә. "Хаҗи Әхрар заманыннан бирле нәкышбәндия - хакимият белән аралашуны мөмкин генә түгел (мәсәлән, сөхрәвәрдия тарикатендәге кебек), ә бәлки, "аларның күңелен яулап алып", халыкка карата алып барылган сәясәтләренә йогынты ясау өчен зарури дип тә исәпләгән бердәнбер юл булып тора. Хуҗа Әхрарның "Дөньялыкта рухи йөкләмәңне башкарып чыгар өчен сәяси хакимияттән файдаланырга кирәк" шигаре нәкышбәндиянең алга таба да иҗтимагый-сәяси активлыгын билгели (эшчәнлек кылу төбәгенә бәйсез рәвештә)". Суфичылыкның Идел-Урал төбәгенә хас сәяси активлыгы шуннан чыгып аңлатыла. Шуңа да, суфиларны (шул исәптән суфи тормышын алып баручыларны да) дөньядан читләшүдә гаепләү - абсолют ялгыш булып, хакыйкатьтән ераклашу булып тора. Аннан да бигрәк, суфичылык ул - җан халәте, һәм дә аны, ниндидер бер кысаларга кертү, асылда, мөмкин түгел.

Китапта гарәп сүзләре һәм гыйбарәләрен тәрҗемә итүдә дә кайбер төгәлсезлекләр булуы күзәтелә: тагъәт - намаз да, табыну да түгел, ә тыңлаучанлык, күндәмлек, Аллаһка итагать итү; мәсҗед-һөҗрә - аерым мәчет түгел, ә бүлмә (һөҗрә); "гобар" - томанны түгел, "тузан"ны аңлата торган, билгеле, бик тирән символик мәгънәгә ия булган суфичылык термины, күп кенә татар суфи шагыйрьләр иҗатында да очрый; кяһиллекдә - ялкаулыкта түгел, ә өлгереп җиткәч (өлкән яшьләрдә); мәкам - хаҗ сәфәре турында язганда кулланылса да, ул гына түгел, ә киң мәгънәсендә суфиларның рухи үсеш баскычлары. Ләкин, алда әйтелгәннәр, бик яхшы сыйфатлы фәнни анализы, гыйльми тикшеренү алымнарының тәңгәллеге һәм тулылыгы белән характерлана торган бу уку-укыту кулланмасының әһәмиятен һич кенә дә киметмиләр. Галимнең күп еллар буе алып барган җентекле хезмәт нәтиҗәсе буларак дөньяга чыккан бу китабы, чыннан да, күптән көтеп алынган һәм дә сирәк очрый торган хезмәт, чөнки ул XVII гасырның күренекле суфи шагыйре Мәүлә Колый иҗатын гына яктыртып калмый, ә бәлки, сәяси-иҗтимагый яссылыкта ул катлаулы чорны күз алдына китереп бастыра.

***Алсу ХӘСӘВНЕХ,***
**филология фәннәре кандидаты,**
**Г.Ибраһимов исемендәге Тел,**
**әдәбият һәм сәнгать**
**институтының өлкән фәнни**
**хезмәткәре**

# МӘДРӘСӘЛӘРНЕҢ ТАТАР МӘГЪРИФӘТЕНӘ КЕРТКӘН ӨЛЕШЕ

### (XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы)

**Патша самодержавиесенең сәясәте татарларга йөзләрчә еллар буена дөньяви мәктәпләр ачарга мөмкинлек бирмәгән. Патша хакимияте татарларның артта калуын мәңгелек итәргә, аларны ярлылыкка, мескенлеккә дучар итәргә, хуҗалык алып баруның, сәнәгатьнең алдынгы рәвешен үзләштерүләрен булдырмаска, фән һәм мәдәниятнең югары казанышларыннан ераграк тотарга тырышкан.**

XIX гасыр ахырына патша строе һәм консерватив даирәләрнең куйган киртәләренә дә карамастан, татар җәмәгатьчелегендә дөньяви белем алуга таба җитди борылыш күзәтелә. Элекке уку-укыту алымнарына күнеккән мәдрәсәләрне реформалау өчен татар буржуазиясенең радикальрәк өлеше, эшлекле даирәләре чыгыш ясый. Аларга гамәли эшчәнлекләрен - сәнәгатьне үстерү өчен, дөньяви белемнәргә аз гына булса да ия хезмәткәрләр кирәк була. Дөньяви белем бирү яклылар арасында Әхмәт һәм Гани Хөсәеновлар, Шакир һәм Закир Рәмиевләр, фабрикант Акчуриннар, Үтәмешевләр, Азимовлар кебек зур сәнәгатьчеләр булганнар. Шул туфракта татар милли хәйриячелеге чәчәк аткан. Хөсәеновларның, аеруча Әхмәт Хөсәеновның (Әхмәт бай), татар рухи мәдәниятенең танылган химаячеләре, яклаучылары булып даны таралган булган. Алар мәчетләр төзүгә, мәктәпләр, мәдрәсәләр ачуга йөзәрләгән мең акчаларын химая иткәннәр, уннарча уку йортларын үз акчаларына яшәткәннәр, аеруча сәләтле шәкертләрне чит ил уку йортларына югары белем, тәҗрибә туплау өчен җибәргәннәр һ. б. Бик олы мөлкәтләргә ия булмасалар да, милли мәгърифәтне үстерүгә, мохтаҗларга ярдәм итүгә һ. б. сизелерлек өлеш кертүче башка химаячеләрнең исемнәрен дә тарих саклап калган. Мәсәлән, Җ.Сәгъдиев дигән сәүдәгәр Казандагы "Касыймия" мәдрәсәсенә - 10 мең сум, мәчетләр һәм мәдрәсәләр төзелеше өчен шулай ук 10 мең сум, Казан хәйрия җәмгыятенә 2 мең сум, бу җәмгыятьнең бала тудыру шифаханәсе бүлегенә 3 мең сум иганә иткән.

Табигый, милли дөньви мәктәпләрне бик каты тыю, аларның дин юнәлешендә генә эшләү мөмкинлекләре булу шартларында, җәдиди мәдрәсәләрдә дини предметларга зур урын бирелгән. Һичбер искәрмәсез, һәрбер мәдрәсәдә төп предметлар итеп, Коръән тәфсире, хәдисләр (пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәләм сүзләре), гакыйдә (иман), фикъһе (шәригать нигезләре) һ. б. куелган. Ләкин яңа дәвер, хакимнәрчә, дөньяви предметлар кертүне таләп иткән, һәм бу яңа предметлар җәдиди мәдрәсәләрнең программаларына тагын да күбрәк кертелә башлаган. Яңага омтылыш татарлар аеруча күпләп яшәгән төбәкләрдә урнашкан мәдрәсәләрдә: "Мөхәммәдия", "Касыймия" (Казан), "Галия" (Уфа), "Хөсәения" (Оренбург), "Рәсүлия" (Троицк), Иж-Бубый (элекке Вятка губернасы Сарапул өязе Әгерҗе волостеның Иж-Бубый авылы) мәдрәсәсендә һ. б. аеруча көчле була. Кайбер җәдиди мәдрәсәләрдә, һичбер искәрмәсез, урта мәктәп курсына керә торган үз вакытының барлык дисциплиналары да (ә кайвакытта, педагогик кадрлар әзерләү зарурлыгы сәбәпле, күбрәк тә) укытылган.

Мәсәлән, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә XX гасыр башында рус теле, арифметика, матур язу, рәсем (сызым), хисап, география, физика (табигать белеме), Россия тарихы, гомуми тарих, төрки халыклар тарихы, фән һәм сыйныфлар тарихы, фәраиз (мирас бүлү турындагы фән), этика, гигиена (тыйб фәне), юриспруденция, метрика, риторика, психология, мантыйк (логика), фәлсәфә, укыту методикасы, педагогика, гарәп теле, фарсы теле, гарәп әдәбияты укытылган. Табигый ки, иншалар (сочинениеләр), изложениеләр язылган, төрле текстлар да ятланган. Татар теленә килгәндә исә, ул гомуми "төрки тел" иseме астында укытылган, ә туган телдә уку исә "кыраәте төрки" (төркичә уку) дип аталган.

"Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә рус телен өйрәнүгә гаять нык игътибар бирелгән. Мәсәлән, башлангыч һәм урта сыйныфларда, 11 ел буена (мәдрәсәдә 1913 елда 14 еллык укыту курсы булган) шәкертләр көн саен рус телен өйрәнгәннәр, ягъни, аңа атнасына алты дәрес бүленгән булган, ә башка предметларга - иң күп дигәндә ике дәрес. Шуңа да, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен тәмамлаучылар рус мәдәниятен пропагандалауга зур өлеш керткәннәр, тәрҗемә эше белән актив шөгыльләнгәннәр.

"Мөхәммәдия"не тулы хаклык белән Октябрьгә кадәрге чордагы татар дарелфөнүне (университеты) дип атау хаклыкка туры килә. Бүгенге көндә дә "Мөхәммәдия" Татарстанның мөселман уку йортлары арасында иң яхшыларыннан санала. 36 ел җәдиди уку йорты булып эшләү дәверендә (1882-1918), аның диварларыннан милләт алгарышына хезмәт куйган меңнәрчә югары хәзерлекле шәхесләр чыккан. Аларны милләтебезнең "энҗе кашы" һәм горурлыгы дип санарга була.

"Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең тышкы күренеше дә игътибарга лаек. 1907 елга ул өч зур таш корпустан торган, ашханәсе, шифаханәсе, аяк киемен тегү һәм ремонтлау, агач эшкәртү, китап төпләү кярханәләре булган. Мәдрәсә территориясендә бакча булган, кышын анда шугалак ясаганнар, шәкертләр анда тимераякта шуа торган булганнар.

Милли мәгариф системасында шулай ук зур мәдрәсә - "Хөсәения" дә әһәмиятле урын биләгән. Анда 8 дини, 20 дөньяви предмет укытканнар. Дөньяви предметлардан татар теле, төрки (татар) әдәбияты, гарәп, фарсы, рус телләре, арифметика, география, тарих, геометрия, зоология, гигиена (тыйб фәне), табигать белеме, химия, логика, этика, фәраиз, гарәп риторикасы, укыту методикасы һ. б. фәннәр укытыла. 1906 елда "Хөсәения" мәдрәсәсе өчен бар уңайлыклары - электр яктыртылуы, пар белән җылыту системасы һ. б. булган өч катлы мәһабәт бина төзелә. Эчке җиһазлауларын искә алмыйча, бинаны төзү үзе генә дә, Әхмәт Хөсәеновка 97 мең сумга төшә. 1907/1908 нче уку елында "Хөсәения"дә 310 шәкерт белем алган. Мәдрәсә персоналы 14 мөгаллим, мөдир, аның урынбасары, 2 тәрбияче, сәркатип, 11 техник хезмәткәрдән торган.

**(Ахыры киләсе санда)**

***Марат хәзрәт МӘРДАНШИН,***
***тарих фәннәре кандидаты,***
***Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге казые***

# Күңел җылылары суынмасын

**Гаҗәеп киң күңелле кешеләр яши Мамадыш районында. Сүзем Түбән Сон авылының иң хөрмәтле кешеләре - абыстайлары турында. Алар белән мине Түбән Сон авылының җирле сәркатибе Вәрәкыя апа Сафина таныштырды.**

Беренче керүемдә үк Таңбикә, Рәсимә абыстайлар минем күңелемдә җылы тойгылар калдырды. Йөзләреннән сафлык, күкрәкләреннән иман нуры бөркелеп торган абыстайларны көннәр буе тыңлап утырсаң да, туймассың, валлаһи! Мөселманлык - ул тырышлык динедер. Абыстайлар үзләренең көчләреннән килгән кадәр авыл халкына ярдәм итеп яшиләр. Мәҗлесләрдә Коръән укыйлар, халыкны вәгазьлиләр, бөтен йолаларны үтәп, кешеләрне соңгы юлга озаталар. Халык бик рәхмәтле аларга. Рәсимә апа лаеклы ялга чыкканчы колхозда сыерлар сауган. Биш бала тәрбияләп үстергәннәр. Ялга чыккач та дингә кереп киткән. Мин аңардан сорыйм: "Рәсимә апа, дин юлына ничек кереп киттең, берәр вакыйга мәҗбүр иттеме әллә?" Бернинди фаҗига дә булмады. Авылларындагы остазы Таңбикә абыстайның намаз укыганнарын күреп, үзлегеннән дини китаплар укып, намазга басарга ният кылган. Таңбикә абыстай да биш бала тәрбияләп үстергән. Миңлекәрам исемле улларының юл һәлакәтенә очрап вафат булуы гына кызганыч. Ике абыстайның да: "Акылыбыз барында кешеләргә дин сабаклары биреп калырга тырышачакбыз, хәзер ахирәт өчен генә эшлибез инде", - диләр. Әлбәттә, аларның тормышы, күргәннәре, эшләре шушы бер язмага гына сыеп бетми. Үзләре әйтмешли, китапка да сыеп бетмәс. Балаларның тәүфигы, иманы бары тик гаиләдәге тәрбиядән килә. Әгәр ата-ана баласын дин кушканча тәрбияләсә, үзе намаз укып, балаларын да кечкенәдән намазлыкка бастырса, хәләл ризык ашатса, Аллаһтан куркып яшәргә кирәклеген аңлатса, замана чиренә әйләнгән, күп кенә ата-аналарны хәвефкә салган, яп-яшь егет-кызларны харап иткән эчкечелек, наркомания ише әйберләр куркыныч булмас, гаиләләрдә тынычлык, тугрылык хөкем сөрер. Укучы балаларга дин сабаклары бирәләр. Шәкертләре районда күп кенә дини конкурсларда алдынгы урыннар яулыйлар. Бу ике абыстай да бик акыллы, сабыр, ярдәмчелләр, күршеләре белән дә туганнарча аралашып яшиләр. Аллаһ аларга озын гомер, күркәм сабырлык, сәламәтлек, җан тынычлыгы, рухи ныклык биреп сөендерсен. Укыган догалары әрвахларга барып ирешсен һәм рухларын шат кылсын иде.

Рәсемдә: *быел 30 апрельдә узган Корьән уку бәйгесендә Рәсимә Сәйфиуллинаның шәкертләре бик күп бүләкләргә ия булды.*

**Фирая МИНГАЛИЕВА,**
**Мамадыш районы**



## *РИУ ректоры Р.МӨХӘММӘТШИН:*

# "Киләчәктә дистанцион белем алу алгы планга чыгачак"

**- Рәфыйк әфәнде, соңгы елларда мәгариф өлкәсендә үзгәртүләр һәм яңалыклар кертү турында күп сөйлиләр. Ислам мәгарифе өлкәсендә яңалыклар кертүгә сез ничек карыйсыз? Россия турында сүз барганда, алар нинди адымнардан башланырга тиеш?**

- Яңалыклар кертү һичшиксез кирәк, без бит мәгариф өлкәсе турында сүз алып барабыз. Шуңа күрә педагогикада кулланыла торган яңа технологияләр мөселман мәгарифе системасында да кулланылырга тиеш. Югыйсә, без дөньядан артта калачакбыз. Минемчә, яңа технологияләр кулланмыйча, уку йортларыннан заманча укымышлы мөселманнарны чыгарып булмаячак. Хәлебездән килгәнчә без дөнья тәҗрибәсендә булган барлык яңалыкларны да кулланырга тырышабыз. Мәсәлән, ике ай элек Согуд Гарәбстанында Ислам дөньясы университетлары федерациясенең (ФУИМ) утырышы узды. Анда Россиядәге генә түгел, ә гомумән бөтен мөселман илләрендәге мәгариф системасының Көнчыгыш Европа мәгариф системасыннан яңалыклар кертү буенча шактый калышуы турында сүз барды. Дистанцион уку формасында белем бирүче уку йортлары челтәреннән торган виртуаль Ислам университетын ачу мәсьәләсе каралды. Нәкъ менә быел без Ислам үсеш банкы белән берлектә ислам икътисады буенча зур проект башлап җибәрәбез. Безгә дистанцион рәвештә ислам икътисады магистрларын әзерләү хокукы бирелде. Быел эшләп китәргә тиешле (шулай ук дистанцион рәвештә белем бирүгә нигезләнгән) тагын бер зур проектта БДБ илләре - әлегә Казакъстан һәм Кыргызстан катнашачак. Теология буенча тулысынча дистанцион рәвештә белем бирү күз алдында тотыла. Читтән торып уку белән чагыштырганда, дистанцион укуның уңай яклары күбрәк - югары уку йорты һәм укытучылар белән һәрвакыт бәйләнештә тору мөмкинлеге бар. Студент көнгә сәгать ярым вакытын белем алуга багышларга тиеш. Мин, дистанцион белем алу киләчәктә алгы планга чыгачак дип уйлыйм, шуңа да мондый белем бирү технологияләре тулысынча кулланылышка керергә тиеш. Шулай да, тотрыклы классик мөселман мәгарифе турында сөйләгәндә гореф-гадәтләр бозылмаска тиеш. Яңа ысуллар белән классик методлар бәйләнештә булырга тиеш. Игътибар иткәнегез бардыр, һәр абруйлы мөселман дин белгече горурланып үз остазының исемен атый яки гыйлем тапшырылу бәйләнеше (иҗазәт) турында сөйли. Һәм моны югалтмаска кирәк. Моның мөселман мәгарифе системасындагы әһәмияте бик зур, бигрәк тә гыйлемнең чылбыр буенча рәсүлебез Мөхәммәдтән (сгв) башлануын истә тотсак. Бу - динне эмоциональ яктан кабул итүдә һәм белем алу ягыннан да бик мөһим. Бездә хәзер иҗазәте булган берничә укытучы (остаз) эшли. Алар студентлар белән индивидуаль дәресләр уздыра. Быел, мәсәлән, без Мароккодан доктор дәрәҗәсенә ия булган дин белгечен чакырып алдык. Ул безнең укытучылар һәм студентлар белән дәресләр үткәрде. Без алга таба да бу тәҗрибәне дәвам итәчәкбез, чөнки, яңа процесслар барлыкка килү белән беррәттән, Пәйгамбәребез (сгв) заманнарыннан килгән гореф-гадәтләрнең юкка чыкмавы бик мөһим.



# БУ — КЫЗЫК!



**Төньяк Каролина университетында эшләүче Америка галимнәре исерткеч эчемлекләрнең фаҗигале вакыйгаларны онытырга ярдәм итмәвен, ә киресенчә, аларны кабат баштан уздырырга мәҗбүр итүен исбатлады, дип яза R&D.Cnews сайты.**

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, исерткеч эчемлекләрне кулланмаган кеше нинди дә булса фаҗигане, мәсәлән, юл фаҗигасен яки якын кешесенең вафатын җиңелрәк кичерә. Ул эчүче кешегә караганда үз хәленә тизрәк кире кайта, фаҗигале вакыйга турында оныта. Исерткеч эчемлекләр куллану кичерешләрне тирәнәйтә генә.

Психик травма кичереп, стресс хәлендә калган кешеләр үз-үзләрен шулай тота. Алар куркыныч янамаган очракларда да куркудан котыла алмый.

Алкоголь тәэсирендә баш миенең префронталь кабыгында урнашкан нерв күзәнәкләрендә үзгәрешләр барлыкка килә. Шулай итеп, галимнәр "эчәргә һәм онытылырга" дигән халык әйтеменең дөрес булмавын, стресс белән алкоголь ярдәмендә көрәшү уңай нәтиҗәгә китермәвен, киресенчә, хәлне авырайтуын раслый.

## Телевидение журналисты Гөлнара Зиннәтуллинага сирәк авырудан дәваланырга ярдәм итик!



Һәрвакыт кояш кебек балкып торган, 47 ел гомерен телевидениегә багышлаган Гөлнара Зиннәтуллинаны авыру аяктан екты. Аңарда бик сирәк чир - "Миеломная болезнь". Химия белән дәвалыйлар. Ул хәзерге вакытта яшәү өчен көрәшә. Чит илдә ярдәм итәргә мөмкиннәр. Ул 12-15 миллион сумга төшәчәк. Ләкин бу кадәр акчаны кешеләр ярдәменнән башка гына җыеп булмый. "Мин бик өметләнәм. Аллаһы Тәгаләгә, дусларыма, хезмәттәшләремә дә ышанам. Үлмәскә дип тырышып яткан көннәрем", - ди Гөлнара Зиннәтуллина. Ярдәм итик Гөлнара апага, аның телефоны - 89172523007.

Авыру аяктан екканда да, оптимист булып кала белә ул, елмаерга да көч таба. Ул хәзер тора да, йөри дә алмый диярлек. Бик кирәк булганда култык таяклары белән генә аягына баса. Ике умыртка сөяге дә сынган. Бу әлеге чир нәтиҗәсе. Өстәвенә түзеп булмаслык сызланулар…

**РЕКВИЗИТЛАР:**

Получатель: Зиннатуллина Гульнара Хабуловна Ленинское отделение 6672 СБ РФ филиал 6672/ 0251

ИНН/КПП: 7707083893/165702001

Р/счёт: 40817810862260422888

Кор/счёт: 30101810600000000603

БИК: 049205603

**Банк получатель:** ОПЕРУ ОСБ "Банк-Татарстан" №8610 г.Казань

**Назначение платежа:** Благотворительная помощь на лечение для зачисления на лицевой счет 40817810862260422888/54 на имя Зиннатуллиной Гульнары Хабуловны





курсы изучения языка

арабский английский

**Российский исламский университет**

**приглашает всех желающих на курсы:**
Арабского и английского языка !!!

**По окончании курсов Вы :**
- приобретёте навыки чтения
- сможете переводить несложные тексты
- научитесь общаться по стандартным темам

**Продолжительность и график обучения:**
Два раза в неделю – один раз в середине недели вечером и один раз в выходной утром.
Общая продолжительность 45 занятий (90 академических часов).
Окончательное расписание составляется с учётом Ваших пожеланий по мере формирования групп.

**Стоимость обучения и оплата**
Оплата за весь курс – 3500,0 рублей.

В случае согласованного прекращения занятий у Вас сохраняется возможность продолжить обучение на данной ступени в последующих группах.

**Адрес:**
Российский исламский университет, г. Казань, ул.Газовая 19.
(остановка «Ипподромная»).

*Чтобы узнать подробнее и записаться на курсы звоните с понедельника по пятницу с 13.00 до 16.00 по телефонам: 8-904-761-48-87, 277-68-15, (ответственный секретарь курсов: Айгуль Рафисовна)*



курсы изучения языка

арабский английский

**Российский исламский университет**

**приглашает всех желающих на курсы:**
Арабского и английского языка !!!

**По окончании курсов Вы :**
- приобретёте навыки чтения
- сможете переводить несложные тексты
- научитесь общаться по стандартным темам

**Продолжительность и график обучения:**
Два раза в неделю – один раз в середине недели вечером и один раз в выходной утром.
Общая продолжительность 45 занятий (90 академических часов).
Окончательное расписание составляется с учётом Ваших пожеланий по мере формирования групп.

**Стоимость обучения и оплата**
Оплата за весь курс – 3500,0 рублей.

В случае согласованного прекращения занятий у Вас сохраняется возможность продолжить обучение на данной ступени в последующих группах.

**Адрес:**
Российский исламский университет, г. Казань, ул.Газовая 19.
(остановка «Ипподромная»).

*Чтобы узнать подробнее и записаться на курсы звоните с понедельника по пятницу с 13.00 до 16.00 по телефонам: 8-904-761-48-87, 277-68-15, (ответственный секретарь курсов: Айгуль Рафисовна)*


## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 15.09.12 | 4:45 | 6:15 | 13:02 | 17:01 | 19:00 | 20:30 |
| *Якшәмбе* | 16.09.12 | 4:47 | 6:17 | 13:02 | 16:59 | 18:58 | 20:28 |
| *Дүшәмбе* | 17.09.12 | 4:49 | 6:19 | 13:02 | 16:57 | 18:55 | 20:25 |
| *Сишәмбе* | 18.09.12 | 4:51 | 6:21 | 13:02 | 16:55 | 18:52 | 20:22 |
| *Чәршәмбе* | 19.09.12 | 4:53 | 6:23 | 13:02 | 16:54 | 18:50 | 20:20 |
| *Пәнҗешәмбе* | 20.09.12 | 4:55 | 6:25 | 13:02 | 16:52 | 18:47 | 20:17 |
| *Җомга* | 21.09.12 | 4:57 | 6:27 | 13:02 | 16:50 | 18:44 | 20:14 |
| *Шимбә* | 22.09.12 | 4:59 | 6:29 | 13:02 | 16:49 | 18:42 | 20:12 |

## "ФӘНИС" мәдрәсәсе шәкертләр кабул итүен дәвам иттерә

***Татарстан Диния нәзарәтенең "Фәнис" мәдрәсәсе тулы һәм тулы булмаган урта белемгә ия булган мөселман егет-кызларын 2012-2013 нче уку елына шәригать (кызлар һәм егетләр өчен) һәм Коръәнхафизлар (кызлар өчен) әзерләү факультетларына укырга чакыра.***

**КӨНДЕЗГЕ БҮЛЕКТӘ - 3 ЕЛ, ЧИТТӘН ТОРЫП УКУ БҮЛЕГЕНДӘ 4 ЕЛ УКЫЙЛАР.**

**Мәдрәсәдән "имам-хатыйб һәм мөгаллим (гарәп теле укытучысы)", "остаз һәм мөгаллимә" белгечлекләре алып чыгалар. Шулай ук теләгән кешеләр "пешекче-кондитер" (кызлар), "электрогазосварщик", "тракторчы һәм "С" категориясенә ия машина йөртүче" (егетләр) белгечлекләре буенча урта махсус белем турында дәүләт дипломы ала алалар. Урта мәктәптә уку мөмкинлеге дә каралган.**

**Мәдрәсәгә укырга керү өчен түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итәргә кирәк:**

***423950 Татарстан, Ютазы районы, Урыссу шәһәр тибындагы посёлогы, Пушкин урамы, 24 йорт.***



***Элемтә өчен телефоннар: +7 (85593) 2-69-07, +7 (85593) 2-68-53; 89172658738, 89274782509.***

***Интернеттагы сайт: http://medrese-fanis.ru/***

Электрон почта: maratmardanshin@rambler.ru


**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 11 (154) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9416.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 13 сентябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).


**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**